| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2021 г. Казань № 170-103/тп-2021

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021 елга тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек берәмлегенә исәпләгәндә «РСК» акционерлык җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү билгеләү турында» 2021 елның 28 июлендәге 125-66/тп-2021 номерлы карары кушымта-сына үзгәрешләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «Җылылык белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик ялгау), җылылык белән тәэмин итү өлкәсендәге хезмәтләрне дискриминацияле булмаган рәвештә күрсәтү мөмкинлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм көчләрен югалткан дип тану турында» 2018 елның 5 июлендәге 787 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплап чыгару буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнен-дәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021 елга тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек берәмлегенә исәпләгәндә «РСК» акционерлык җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү билгеләү турында» 2021 елның 28 июлендәге 125-66/тп-2021 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2.1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.2.1.2 | 251-400 мм | 418,947»; |

2.2.2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.2.2.2 | 251-400 мм | 2 866,056». |

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром